| ГЛАВА СТАРОКАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**от 20.03.2024г.** **№ 2**

«Иске Кәшер авыл җирлеге Иске Кәшер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Урта Кәшер торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Яхшыбай торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТӘ:**

1.2024 елның 30 мартында 16.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Урта Кәшер торак пункты, Хади Такташ урамы, 38а йорт адресы буенча урнашкан Урта Кәшер авылы клубы бинасында «Иске Кәшер авыл җирлеге Урта Кәшер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Урта Кәшер торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Иске Кәшер авыл җирлеге Урта Кәшер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Урта Кәшер торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Урта Кәшер торак пунктында урам яктырту челтәрләрен (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау);
2. Урта Кәшер торак пунктында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Һади Такташ урамында вак таш япмасын ремонтлау (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, вак таш ташу һәм җәю, грейдирование)
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Урта Кәшер торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка өчен ягулык-майлау материаллары, ЗИЛ-131 автомашинасы Беларусь МТЗ 82.1 тракторы; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы ,ЗИЛ-131 автомашинасы өчен запас частьләр);
4. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Ремонт, коймалар төзү, төзелеш материаллары һәм инвентарь( триммер һәм бензопила) сатып алу, эш өчен түләү );

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Иске Кәшер авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка чыгарырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районының
Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы /Р.Н.Дәүләтҗанов/